| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.05 2023 ел Болгар ш. № 353

Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» РФ Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас районы буенча махсус хәрби операциядә һәлак булган (үлгән) катнашучыларның туганнарына ярдәм күрсәтү максатларында

КАРАР ИТӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибен расларга.
2. «Спас муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 04.05 маендагы 353 номерлы карарына кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарны җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында яшәүче түбәндәге категория гражданнарны (алга таба – хәрби хезмәткәрләрне)җирләү белән бәйле ритуаль хезмәтләр өчен түләү механизмын билгели:

а) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

б) Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар;

в) Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар,

г) махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар;

д) махсус операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре.

2. Җирләүне оештыру, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы торак пунктларының башкарма комитетлары (алга таба - башкарма комитетлар) тарафыннан үлем турында документлар (үлем турында белешмә, үлем турында хәбәр, үлем турында таныклык) нигезендә башкарыла.

3. Һәлак булган хәрбиләрне җирләү Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары тарафыннан билгеләнгән җирләү урыннарында, һәлак булган кешенең (үлгән кешенең) үлемнән соң аның тәненә лаеклы мөнәсәбәте турында ихтыяр белдерүенә ярашлы рәвештә, әгәр ихтыяр белдерүне үтәү мөмкин булмаган шартлар килеп чыкмаса яки Россия Федерациясе законнары белән башкача билгеләнмәсә, башкарыла.

4. Үлгән кешенең ихтыяры булмаса, аның җирләү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү хокукына хатыны (ире), якын туганнары (балалар, ата - аналар, уллыкка алынганнар, уллыкка алучылар, туган абыйлары һәм туган апалары, онықлары, бабасы ,абисе), башка туганнары (алга таба туганнары дип атала) ия.

5. Һәлак булган хәрби хезмәткәрне җирләүне оештыру Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына йөкләнә.

6. Ритуаль хезмәтләрнең түбәндәге төрләре түләнергә тиеш:

- үлгән кешене моргка күчерү, морг хезмәтләре;
- кабер, урна, тәре, койма, венок, чәчәкләр бирү һәм китерү;
- җирләү;

- искә алу мәҗлесе;

- транспорт хезмәтләре күрсәтү.

7. Ритуаль хезмәтләр өчен түләү фактик чыгымнар буенча башкарма комитетлар тарафыннан расланган финанс документлары (килешү, башкарылган эшләр акты, счет, накладная, товар чек) белән башкарыла.